ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422701, Высокогорский район РТ,
с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д.113 А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИЕКТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422701, ТР Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл ур.113 А

Тел./факс: +7(84365) 74-778, e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
28.06.2024

КАРАР
11

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 нче елның 6 нчы декабрендәге 25 нче номерлы карарына «Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслауга» үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 нче елның 6 нчы декабрендәге 25 нче номерлы «Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге территориясендә адреслар бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм бетерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче бүлекнең 1.2 нче пунктының 10 нчы абзацында «Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «Гариза белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 1 нче бүлекнең 1.5 нче пунктының 9 нчы абзацында “(шулай ук торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы)” сүзләреннән соң “яр буе” сүзен өстәргә.

1 нче бүлекнең 1.5 нче пунктының 10 нчы абзацында “яр буе,” сүзен төшереп калдырырга.

1.3. 2.3.2 нче бүлекнең 2.3 нче пунктында «берләшергә мөмкин» сүзләрен «берләшә» сүзенә алмаштырырга.

1.4. 2.4 нче бүлегенең 2.4.1 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы:

- кәгазьдә гариза бирелгән очракта - гариза кабул ителгән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт аралыгында;

- гаризаны электрон документ формасында биргән очракта - гариза кабул ителгән көннән соң 5 эш көне эчендә.

Муниципаль хезмәт алдан (актив) режимда күрсәтелгән очракта - регламентның 1.6 нчы пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән алып 3 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.»

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ф.Салахутдинов